**Ф.Х.Габдрахманова**
*Казанский (Приволжский) федеральный университет*

## Татар паремияләрендә *акыл* лексемасының бирелеше

*лингвокультурология, паремия, лексема «акыл», татарский язык*

Лингвокультурологиянең мәкаль һәм әйтемнәр белән кызыксынуы паремияләрнең сүздә гәүдәләндерелгән «халык аңы стереотиплары» булуы белән аңлатыла. Шулай итеп, паремияләрне өйрәнү, беренчедән, телдәге мәгънәләрнең мәдәният белән билгеләнүен ачыкларга һәм, икенчедән, мөһим мәдәният стереотиплары формалашуның когнетив юлларын карарга мөмкинлек бирә [Замалетдинов 2010: 73].

Шушы аспекттан чыгып, *акыл* лексемасы кергән мәкаль һәм әйтемнәргә мөрәҗәгать итик:

*11403 Акыл базарда сатылмый.*

Белгәнебезчә, безнең халык элек-электән сәүдә эше белән шөгелләнгән. Бу, үз чиратында, халык аңында һәм телендә чагылыш тапкан. Базарда бөтен әйберне сатып алып була, ләкин *акыл* алып булмый. Ягъни акыл акча, алтын кебек материаль байлыкларга бәйле булмаган, алардан күпкә кыйммәтлерәк әйбер икәне күрсәтелә. Мондый фикер татар халык мәкальләренең күпчелегендә күзәтелә. Мәсәлән:

*11406. Акыл белән алтын табыла, алтын белән акыл табылмый.*

*11493. Алтын кирәк түгел, акыл кирәк.*

Мәкальләрдә акылның үзе зур байлык икәнлеге аңлашыла:

*11403. Акыл байлыгы – тузмас байлык.*

*11421. Акылдан зур байлык, наданлыктан зур ярлылык, киңәштән зур таяныч юк.*

Икенче төркем мәкальләрдә акылның көчкә, буйга, яшькә бәйле түгеллеге искәртеп үтелә:

*11408. Акыл буй белән үлчәнми.*

*11414. Акыл сакал белән бергә үсми.*

*11418. Акыл яшьтә түгел – баштa.*

Шулайда бер иш мәкальләрдә *акылның* нигезе тәҗрибә икәнлеге аңлашыла:

*11405. Акыл баскыч башында үсми.*

*11416. Акыл төбе – тәҗрибә.*

*11417. Акыл юлда чәчелеп ятмый.*

Түбәндәге мәкальләрдә акылның бәлаләрдән котылу чарасы, кешенең төп ярдәмче сыйфаты икәненә басым ясала:

*11407. Акыл белән эш итү – мең бәланың калканы.*

*11410. Акыл булса, юл бар.*

Татар халкында ниндидер нәтиҗәгә килү өчен көчләрне берләштерү турында, ягъни кумәк, бердәмләшеп, киңәшләшеп эшләүне хуп күргән мәкальләр дә шактый:

*11419. Акылга акылны кушкач, чын акыл туа.*

*11534. Бер акыл – ярты акыл, ике акыл – тулы акыл.*

*11535. Бер акылдан ике акыл яхшырак.*

Тагын бер төркем мәкальләрдән без акылның әдәп белән аерылгысыз булуын күрәбез:

*11426. Акыллы атын мактар, кыланчык үзен мактар.*

*11433. Акыллы кеше башкаларга иткән ярдәме белән мактанмас.*

*11440. Акыллы сүзен «мин» дип башламас.*

*11473. Акылның кадере әдәп белән, байлыкның кадере юмартлык белән, куәтнең кадере баһадирлык белән.*

*11475. Акылның урыны мидә, нуры күңелдә.*

Тагын бер кызыклы мәкальләрнең берсе: *11411. Акыл – дәрья, уй – дингез.* Әлеге мәкальдә акылның масштабын күрсәтер өчен *дәрья* сүзе кулланыла.

Татар телендә шулай ук акыл белән ахмаклык капма-каршы куелып бирелгән мәкальләр дә бик күп:

*11428. Акыллы аңына алганчы, юләр сөйләп бетерер.*

*11429. Акыллы белән эш йөртсәң – акыл җыярсың, юләр белән эш йөртсәң – үз акылыңны җуярсын.*

*11431. Акыллы ир – ил агасы, акылсыз ир – ил бәласе.*

*11447. Акыллы хезмәтенә таяныр, ахмак – өметенә.*

*11469. Акыллының чәчен ахмак агартыр һ.б.*

Күргәнебезчә, мәкальләр – телнең үзенчәлекле бер күренеше, аларга күчерелмә мәгънәлелек хас. Гади сүздән аермалы буларак, алар фикерне сурәтле, бизәкле, тәэсирле итеп белдерәләр. Кеше үзенең сөйләмендә мәкаль-әйтемнәр, фразеологик берәмлекләрдән ни дәрәҗәдә мул һәм уңышлы файдаланса, аның фикере кешеләргә шул дәрәҗәдә җиңелрәк, тизрәк һәм күркәмрәк булып ирешә. *Акыл* лексемасы кергән татар халык мәкаль һәм әйтемнәре аша борынгы бабаларыбыз безгә *акылның бик зур байлык* икәнлеген, аның *тәҗрибә белән тупланиуын*, акыллы кешенең *әдәпле һәм зирәк булганлыгын* искәртә, *күмәкләшеп, киңәшләшеп эшләргә* куша.

**Әдәбият**

Замалетдинов Р.Р. О роли пословиц в исследовании национально-культурных особенностей языкового сознания / Р.Р.Замалетдинов, Г.Ф.Замалетдинова // Вестник ТГГПУ. – 2010. – № 2 (20). – С. 73–78.

Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. 3 томда. Т.I. / Н.Исәнбәт. – Казан: Татар. кит.нәшр., 1959. – 959 б.